# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **25.11.2023 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ керүче
Буралы авылында 2024 елда үзара салым
жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чуар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Буралы авылы җирлегендә гражданнар җыены гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Сез, 2024 елда, Чуар –Абдул авыл җирлеге составына керүче Буралы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- урам яктырту челтәрләрен урнаштыру (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру)
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(грейдер белән юлларны тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрьская урамы, 34 йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов